# Олпат галим юбилее

***(Кукмара мәдрәсәсендә күренекле татар дин галиме Шиһабеддин Мәрҗанинең 200 еллык юбилеена багышланган чарада мәдрәсә мөгаллимәсе Рузилә абыстай Мәҗитованың ясаган чыгышы)***

2018 елда татар җәмәгатьчелеге күренекле татар дин галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең 200 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Шул уңайдан агымдагы ел Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния Нәзарәте тарафыннан “Мәрҗани елы” дип игълан ителде.

Мәшһүр татар мәгърифәтчесе, дин әһеле, этнограф, археограф, шәркыять галиме, имам-хатыйб, мөгаллим Шиһабетдин Мәрҗани 1818 елның 16 гыйнварында Казан өязенең (хәзерге Әтнә районы) Ябынчы (Япанчы) авылында имам-мөдәррисләр гаиләсендә туа. Аның Габделкотдус исемле бабасы Мәрҗани авылы кешесе була. Соңыннан Шиһабетдин хәзрәт бу авыл исемен үзенең тәхәллүсе (псевдоним) итеп ала.

Мәрҗанинең ике як бабалары да гыйлем ияләре була: Коръән һәм фикыһ фәннәренә кагылышлы белемне булачак галим Габденнасыйр бабасыннан өйрәнә, тарих гыйлемен исә Сөбхән исемле бабасыннан ала.

1823 елда, Мәрҗанигә 5 яшь чагында, аның әнисе Хөбәйбә Габденнасыйр кызы вафат була һәм ул үги ана тәрбиясенә кала (шул үги анасы кырыс кеше була дигән истәлекләр сакланган). Әтисе Баһаветдин Ташкичү авылы мәдрәсәсендә мөгаллимлек итә (ул Бохарада гыйлем алган була). Әтисеннән Шиһабетдин гарәп телен, логиканы (мантыйк) һәм каләмне (теология) өйрәнә.

17 яшендә Шиһабетдин Мәрҗани үзе дә Ташкичү мәдрәсәсендә укыта башлый. Шул вакытта кулланыла торган дәреслекләрнең сыйфатыннан канәгать калмыйча, ул мөстәкыйль рәвештә өстәмә гыйлемнәр алып, укыту өчен үзенә дәреслек төзи.

Гыйлемгә зур омтылышы булган егет 1838 елда (20 яшендә) Бохарага китә. Ул вакытта дан тоткан Бохара һәм Сәмәркand мәдрәсәләре фәнни үзәк булып кайнап тора. Әмма укый башлагач, үткен зиһенле Шиһабетдин биредәге укыту искечә алып барылганын, катып калган бер системага корылганын аңлап ала һәм гыйлем бирү системасын, уку-укыту методикасын яңартырга тәкъдим итә. Әмма иске карашлы дин әһелләре тарафыннан аның бу тәкъдимнәре хупланмый. Шуннан соң Ш. Мәрҗани җирле байларның балаларын укытып көн күрә һәм Бохараның бай китапханәләрендә үзлектән шөгыльлләнеп, ислам галимнәре туплаган бай мирасны тирәнтен өйрәнә.

25 яшендә (1843 елда) ул Сәмәркандка китә һәм анда “Шәрдар” исемле мәдрәсәгә укырга керә. Гыйлем сөюче буларак, шунда ул мәшһүр тарихчы, казый Әбү Сәгыйд-әс-Сәмәрканди белән таныша, шушы кешенең өендәге китапханәсендә еш булып, белем эсти. Шул вакытта аның реформаторлык идеялары тагын да ныгый һәм камилләшә.

Сәмаркандта ике ел торганнан соң, 1845 елда Шиһабетдин Мәрҗани янә Бохарага кайта. Биредә ул “Мир гарәп” исемле мәдрәсәгә урнаша һәм Әл-Фәраби, Әбүгалисина, Ибн Рөшд кебек бөек акыл ияләренең әсәрләрен өйрәнә. Бу вакытта ул үзе дә олы

гыйлем юлында беренче адымнарын ясый һәм җәмәгатьчелеккә дини уку йортларының укыту системасына ризасызлыгын белдереп, яңалык кертергә омтылучы дин эшлеклесе буларак танылa.

1849 елда, 31 яшендә Шиһабетдин Мәрҗани туган ягына кайта. Бер имтиханын Казанда, икенчесен Уфада – мөфтигә тапшырганнан соң, 1850 елда яшь галим Казанның беренче мәчетенә имам итеп билгеләнә. Шиһабетдин хәзрәт үз алдына мөселманнарның үзаңын яңартырга кирәк дигән олы максат куя. Ләкин консерватив (искечә фикерләүче) муллалар моны ошатмыйча, Диния Нәзарәтенә әләк-шикаятьләр язарга тотына. Шул шикаятьләр аркасында Мәрҗанине ике тапкыр эшеннән алалар, әмма бераздан яңадан үз урынына кире кайтаралар.

50 яшендә Шиһабетдин Мәрҗани Казан шәһәренең мөхтәсибе итеп сайлана. Ул киң тарафлы эшкә керешә: рәсми хәкимият белән элемтә урнаштыра, Казан типографиясендә Коръән китабын бастыруга күзәтчелек итә (соңрак бу хакта тарихи китабын бастырып чыгара), җир тетрәүдә зыян күргән Кавказ халкына акча җыюны оештыра, мөселманнарның тууы, үлүе, никах теркәүләре турында хисаплар төзи, шулай ук мөселманнарның суд утырышларында катнаша.

1869 елда, Казан губернаторы үтенече буенча, Шиһабетдин Мәрҗани мөселман җәмгыятенә адресланган “Хайваннарга шәфкатьле булу турында” дигән мөрәҗәгать яза. Бу хат бастырылып, мөселман авылларына таратыла. Бу эше өчен Мәрҗани губернаторның Рәхмәт хатына лаек була.

1870 елда галимнең “Нәзаратүл-хак” дигән китабы дөнья күрә. Бу хезмәт киң тарала, хәтта Һиндстан, Сурия, Урта Көнчыгышта популярлык казана. Шулай итеп, Мәрҗанинең исеме, даны еракларга барып җитә.

1870-80 нче елларда Шиһабетдин Мәрҗани үзенең иҗатын мәгърифәтчелек белән бәйли. Ул Казан университеты профессорлары, академиклары белән танышып, алар белән аралаша, шул ук вакытта тарих, этнография өлкәсендәге эшчәнлеге белән дә танылa.

1876 елда Казанда “татар укытучысы” мәктәбе ачыла. Мәктәп башлангыч сыйныф укытучылары әзерли. Шиһабетдин Мәрҗани анда 9 ел буена дин сабагын укыта.

1880 елның 31 августында ул хаҗ сәфәренә китә: Түбән Новгород, Мәскәү, Курск, Киев, Одесса, Стамбул, Измир, Александрия, Каир, Сүәш шәһәрләре аша сәфәр кыла. Бу озын сәфәрдә ул үз чорының күренекле галимнәре, дин, дәүләт эшлеклеләре белән очраша. Бу вакытта ул инде танылган галим була (аны хәтта Мәккә галимнәре дә белгән була).

Шиһабетдин Мәрҗани 1889 елда вафат була. Үзеннән соң ул күп шәкертләр калдыра. Алар арасында Муса Бигиев, Галимҗан Баруди, Ризаэтдин Фәхретдин, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйри кебек танылган шәхесләр дә була.

Мәрҗани Рәсәйдә җәдидчелек хәрәкәтен башлап җибәрүче галим буларак билгеле. Мәдрәсәләрдә укыту реформасын, татар халкының бөтен дөнья мәдәнияте һәм фән казанышларын үзләштерү нигезләрен ул сала.

Рузилә Мәҗитова,
Кукмара мәдрәсәсе мөгаллимәсе.